**ТР Актаныш муниципаль районы Богады төп гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Галләмова Гөлназ Мөбәрәк кызы төзегән “Кече яшьтәге мәктәп укучыларының танып-белү активлыгын үстерүдә инновацион технологияләр” исемле проект эшенә**

**рецензия**

Белем бирүдә яңа технологияләр куллану–заман таләбе. Шундый технологияләрнең берсе- мәгълүмати-коммуникатив технология. ФГОС шартларында мәгълүмати технологияләр куллану бик кулай. Дәрестә мәгълүмати- коммуникатив технологияләр куллану укытучыга вакытны дөрес файдаланырга, дәресне мавыктыргыч һәм кызыклы итеп оештырырга ярдәм итә, укучыларның игътибарын ныграк җәлеп итә.

Әлеге проект эшенең максаты: инновацион технологияләр кулланып, укучыларның иҗади фикер йөртү сәләтләрен, танып-белү активлыкларын үстерерү, белем алуга кызыксыну уяту, белем бирүнең сыйфатын күтәрү.

Проект эше күләме, төзелешенә куелган таләпләргә туры килә. Проектның идеясе төгәл формалаштырылган, тормышка ашыру урыны, вакыты, этаплары төгәл күрсәтелгән, бурычлар билгеләнгән. Ул түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала: кереш өлеш (максат һәм бурычлар, көтелгән белем нәтиҗәләре, тормышка ашыру урыны, вакыты, чаралар планы), төп бүлек, файдаланылган әдәбият исемлеге, кушымта. Төп өлешнең беренче бүлегендә инновацион технологияләр турында мәгълүмат бирелә. Икенче бүлектә дәресләрдә укучыларның танып-белү активлыгын үстерүдә зур урын уйный торган инновацион технологияләр күрсәтелә. Өченче бүлектә белем бирүдә кулланылучы мәгълүмати технологияләр һәм электрон белем чыганаклары атала. Дүртенче бүлектә укытучы тарафыннан төзелгән проект эшләре тәкъдим ителә, аларны куллану үзенчәлекләре яктыртыла. Бу хезмәтләр укытучының эш тәҗрибәсен практикада кулланауын күрсәтә.

Укытучы эшкә иҗади якын килеп, күп фәнни хезмәтләрдән файдаланып, аларны урынлы кулланып эшләгән. Эчтәлек темага тәңгәл килә. Хезмәттә фәннилек, системалылык, фикер төгәллеге сакланган.

Нәтиҗә: дәресләрдә укучыларның танып-белү активлыгын үстерүдә мәгълүмати-коммуникатив технологияләрне кулланып укыту тәҗрибәсе актуаль, методик яктан нигезле һәм практик яктан әһәмиятле. Тулысынча федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә. Куелган максат һәм бурычлар укучыда фәнгә карата кызыксыну уята, танып-белү активлыгын үстерә, белем бирүнең сыйфатын күтәрергә ярдәм итә.

Әлеге хезмәт тиешле таләпләргә җавап бирә һәм уңай яктан бәяләнә.

**Рецензент:**

Галиуллин Радик Рамилевич, канд. филол. наук,
доцент, доцент кафедры русской и татарской
филологии ФГБОУ ВО “НГПУ”

МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ИНСТИТУТ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ПРОФЕССИОНАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ИНН 1650017589